*Муниципаль тур*

**Татар телендә гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен татар теленнән олимпиада биремнәренең ҖАВАПЛАРЫ**
**2024-2025 нче уку елы**
**4 нче сыйныф**

**Максималь балл – 50**

**I. ТЕСТ (18 балл)**

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| **2** | **1** | **3** | **3** | **2** | **4** | **4** | **3** | **3** |

**II. Теоретик бирем.**

Синонимнар турында языгыз. Фикерегезне мисаллар белән дәлилләгез. (**5 балл**)

Укучы мәктәп программасы, дәреслекләрдә бирелгән материалны мөмкин кадәр тулы чагылдырган очракта, биремгә иң югары балл куела. Төгәлсезлекләрнең күләменә карап, баллар саны кимetelә. Мәгълүмат бөтенләй булмаган очракта, укучыга 0 балл куела.

**I. Уйлагыз һәм җавапларны языгыз.**

Фразеологик әйтелмә һәм аның мәгънәсен тәңгәлләштерегез, җавапны саннар белән языгыз. **(5 балл)**

| | |
|---|---|
| А) кул арасына керү | 1) сөйләргә теләү |
| Ә) тел кычыту | 2) кузгалу |
| Б) хәрәкәткә килү | 3) карау |
| В) тел бистәсе | 4) күп сөйләүче |
| Г) күз төшерү | 5) булышу |

**Җавап : 51243**

**IV. Гамәли-иҗади бирем.**

1. Җәя эчендәге сүзләрнең дөресен сайлап, астына сызыгыз. **(4 балл)**

Беркөнне мин Аккүлгә киттем. Тын гына (утырган / барган / **яткан**) көзге күл өстенә ялтырап юл салынган. Күлнең бер читендә кыр казлары әрле-бирле (утыралар / **йөриләр** / шаяралар).

Камышларны ике якка аерып, суга (бардым /**кердем** / чыктым). Анда, сыңар канаты белән талпынып, бер кыр казы очарга маташа, (бәлки / **ләкин** / гаять) оча алмый, туктый. Мин аны җиңел генә тотып, өйгә алып кайттым. (*Г. Ахунов*)

2. Шигырьне укыгыз һәм күп нокталар урынына тиешле хәрефләрне куегыз. **(4 балл)**

Әти гармун уйный өйдә,
Бармаклар йөгЕреп тора.
Күпме кӨйләр белә бит ул,
БиГрәкләр дә булдыра.
Әти уйный, ә мин биим,
Курчаклар карап тОра. (*Т. Галимуллина*)

3. Шигырьдән *әни* сүзенең антонимын күчереп языгыз. **(2 балл)**

**Әти**

4. *Күпме* сүзенә аваз-хәреф анализы ясагыз. **(5 балл)**

5 хәреф, 5 аваз

Сузык авазлар: [ү] – иренләшкән нечкә сузык; [э] – иренләшмәгән нечкә сузык. Тартык авазлар: [к]– саңгырау тартык; [п] - саңгырау тартык; [м] – яңгырау.

6. “Кышкы урманда” темасына 6-7 җөмләдән торган инша языгыз. (**7 балл**)